КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 24 сентябрь г.Казань № 913

Татарстан Республикасында территорияләрне комплекслы үстерү проектларын тормышка ашыру чаралары турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасында территорияләрне комплекслы үстерү проектларын тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Җирле администрация башлыгы тарафыннан әзерләнгән территорияне комплекслы үстерү турындагы карар проектын шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы белән килештерү тәртибен;

Территорияне комплекслы үстерү турындагы карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки җирле администрация башлыгы тарафыннан кабул ителгән очракта, комплекслы үстерелергә тиешле территориянең чикләрен билгеләү тәртибен;

Территорияне комплекслы үстерү турындагы карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки җирле администрация башлыгы тарафыннан кабул ителгән очракта, территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү хокукына торгларның башлангыч бәясен билгеләү тәртибен;

Җирле үзидарә органнарының җир кишәрлекләренә һәм (яки) аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларына хокукый ия булучылар белән, территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү хокукына торглар үткәрмичә, мондый шартнамәне төзү тәртибен;

Комплекслы үстерелергә тиешле торак йортлы территория чикләренә кертелгән күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре тарафыннан өстәмә түләүгә, үзләренә бирелә торган торак урыннар белән чагыштырганда, мәйданы зуррак булган торак урыннар һәм (яки) бүлмәләр саны күбрәк булган торак урыннар сатып алу тәртибен;

Торак йортлар салынган территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территориядә урнашкан күпфатирлы йорттагы барлык урыннарга милек хокукы күчкәннән соң, махсус счет хуҗасы тарафыннан хокукны Татарстан Республикасының яки муниципаль берәмлекнең махсус счетына тапшыру тәртибен;

Территорияне комплекслы үстерү турындагы карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки җирле администрация башлыгы тарафыннан кабул ителгән очракта, территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны тормышка ашыру тәртибен;

Комплекслы үстерелергә тиешле торак йортлы территория чикләренә кертелгән күпфатирлы йорттагы бушатыла торган торак урын өчен алмашка бирелә торган торак урын туры килергә тиешле торак урын стандартларын;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки җирле администрация башлыгы тарафыннан кабул ителә торган территорияне комплекслы үстерү турындагы карарларда күрсәтелә торган капиталь төзелеш объектлары турында мәгълүматлар, аларның рөхсәт ителгән төзелеше һәм реконструкциясенең иң чик параметрлары исемлеген.

2. Авария хәлендә дип танылмаган һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле булган, торак йортлар салынган территорияне комплекслы үстерү гамәлгә ашырыла торган торак йортлы территория чикләрендә урнашкан күпфатирлы йортларның конструктив элементларын һәм күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәт составына керә торган йортлар эчендәге инженерлык-техник тәэмин итү системаларын капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтүнең һәм (яки) эшләр башкаруның җыелма кыйммәтен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты-ның «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» 2013 ел, 29 июнь, 450 нче карары белән билгеләнгән капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләме нигезендә формалаштырылган күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау фонды акчасы исәбеннән төбәк операторы тарафыннан түләнә алган күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкаруның иң чик кыйммәте күләменә тигез итеп, торак урыннарның 1 кв.метр гомуми мәйданы исәбеннән чыгып билгеләргә.

3. Авария хәлендә дип танылмаган, сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле булган һәм торак йортлар салынган территорияне комплекслы үстерү турындагы карар проектына кертелгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышларын үткәрүнең иң чик срогы норматив хокукый актларны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә торак йортлар төзү территориясен комплекслы үстерү турындагы карар проектын бастырып чыгарган көннән 60 календарь көн тәшкил итә дип билгеләргә.

4. Территорияне комплекслы үстерү турындагы карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгын торак йортлар салынган территорияне комплекслы үстерү турындагы карар проектын, торак булмаган биналар салынган территорияне комплекслы үстерү турындагы карар проектын, буш территорияне комплекслы үстерү турындагы карар проектын әзерләүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы итеп билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин